ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2020 Казан ш. № 587-45/тко-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хаталарны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 19.12.2019 №11-54/тко карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 №585-43/тко-2020 карары керткән үзгәреш белән) кушымтасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

таблицадагы «Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар, сум/куб.м.» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар, сум/куб.м» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасында «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 19.12.2019 №11-55/тко карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 №584-42/тко-2020 карары керткән үзгәреш белән) кушымтасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

таблицадагы «Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар, сум/куб.м.» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар, сум/куб.м» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019

№ 11-29/тко карарның 1 нче кушымтасы исеменә (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №561-21/тко-2020 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020-2022 елларга «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән чик тарифлар».

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром